Әлмәт шәһәре Башкарма комитеты

«18» декабрь 2019 ел №108

Җир кишәрлегеннән һәм капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2009 елның 25 декабрендәге 366 номерлы карары белән расланган «Әлмәт шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре нигезендә, Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төрләре классификаторын раслау турында» 2015 елның 30 сентябрендәге 709 номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2009 елның 25 декабрендәге 366 номерлы карары белән расланган "Әлмәт шәһәре" муниципаль берәмлеге Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре белән, Әлмәт шәһәре башлыгының 2019 елның 20 ноябрендәге 38 номерлы «Җәмәгать тыңлауларын билгеләү турында»гы карары нигезендә 2019 елның 5 декабрендәге 9725и номерлы гавами тыңлаулар нәтиҗәләре бәяләмәсе нигезендә (“Альметьевский вестник” газетасы 2019 елның 12 декабарендәге 51 номерлы басмасы),

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Җир кишәрлегеннән һәм капиталь төзелеш объектыннан шартлы рәвештә рөхсәт ителгән файдалану төренә - «бокс тибындагы гаражлар, күп катлы, җир асты һәм җир өсте гаражлары, аерым җир кишәрлегендәге төрләре классификаторы , код- «автотранспортны саклау» 2.7.1 номерлы, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Әлмәт муниципаль районы, Әлмәт шәһәре, Тельман ур. адресы буенча 12 148 кв.м мәйданлы җир кишәрлегенә карата.

2. «Әлмәт муниципаль районы архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсе» муниципаль бюджет учреждениесенә (Мордагулова Р.Р.) әлеге карарны Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасына (Пузырева И.Г.) җибәрергә.

3. Район башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталына (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны төзелеш буенча башкарма комитет җитәкчесе урынбасары вазыйфаларын башкаручы А.Н.Подоваловка йөкләргә.

Шәһәр Башкарма  комитеты җитәкчесе Л.Ф. Валеев